وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№17 (212). 8 ноябрь 2013/5-мөхәррәм-1435

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ


# АЛЛАҺНЫҢ ЧИКСЕЗ РӘХМӘТЕНӘ ИРЕШЕРГӘ ЯЗСЫН!



**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!**
**Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!**

Мөкатдәс мөхәррәм аенда бер олы көн - · Гашүрә көне бар. Ул мөхәррәм аеның 10 нчы көненә, ә милади календарь буенча быел 13 нче ноябрьгә туры килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам, Мәккәи Мөкәррәмә шәһәреннән Мәдинәи Мөнәүвәрә шәһәренә һиҗрәт кылганнан соң, шушы шәһәрдә яшәгән яһүдләрнең бу көндә ураза тотканнарын күргән һәм алардан моның сәбәбен сораган. Яһүдләр: "Бу көнне Аллаһы Тәгалә пәйгамбәребез Муса галәйһиссәламне Фиргавеннән һәм аның гаскәреннән коткарган. Шуңа күрә без бу көнне олылап ураза тотабыз", - дип әйткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәлам аларга болай дип җавап биргән: "Сезгә караганда Муса пәйгамбәр безгә якынрак". Рәсүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам шушы көнне уразада булган. Ул үзенең өммәтен, мөэминмөселманнарны да бу көндә ураза тотарга өндәгән. Гашүрә көнендә башка күп кенә бөек вакыйгалар да булган. Бу көнне Бөек Раббыбыз дөньяны, Адәм галәйһиссәламне яралткан, Нух галәйһиссәламнең көймәсе тауга килеп җиткән, Ибраһим галәйһиссәлам туган һәм мәҗүсиләрнең учагыннан коткарылган, Әюб галәйһиссәлам авыруыннан терелгән, Йосыф галәйһиссәлам олы дәрәҗәләргә ия булган һ. б.

Мөхәррәм ае да рәҗәп, рамазан айлары кебек үк изге-шәрәф ай булып санала. Ай буе ураза тоту хәлебездән килмәсә, без Гашүрә көненең унынчы һәм унберенче көннәрендә генә булса да ураза тотарга тырышырга тиешбез. Ә иң хәерлесе - рәттән өч көн ураза тоту. Мөхәррәм аеның 9 нчы, 10 нчы һәм 11 нче көннәрен ураза белән уздырсак, Аллаһның чиксез рәхмәтләренә ирешербез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәссәламнән: "Мөхәррәм аеның Гашүрә көнендә ураза тотсаң нинди савапларга ирешергә була соң?" - дип сорагач, ул: "Узган елыгызның гөнаһларын, хата-кимчелекләрен Аллаһы Тәгалә гафу итәр, истигъфар кылыр", - дигән. Шулай ук бу көнне сәдака өләшү, сабыйларны, якыннарыңны сөендерү, Коръән сүрәләре, догалар уку саваплы гамәлләрдән санала.

Аллаһ Раббыбыздан гөнаһларыбызны ярлыкавын өмет итеп мөхәррәм аенда тоткан уразаларыбыз кабуллардан булса иде, Аның чиксез рәхмәтенә, дөнья-ахирәт бәхетсәгадәтенә ирешергә насыйп итсә иде.

*Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,*
*Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе*

# ТРАДИЦИОН ИСЛАМ ТИРӘСЕНДӘГЕ МӘГЪНӘВИ КҮПТӨРЛЕЛЕК

**2009 нчы елның августында Россия мөфтиләре белән очрашкан вакытта Дмитрий Медведев уңайсыз хәлдә калды. Ул вакытта Дмитрий Анатольевич Россия Президенты иде, һәм традицион исламны яклап чыгыш ясады. Илнең дини лидерларының берсе дәүләт башлыгыннан бу гыйбарәне кулланмавын үтенгәч, Президентка да, очрашуда катнашучыларга да уңайсыз булган иде.**

"Традицион ислам" төшенчәсе Россия мөселманнарының бүгенге хәле контекстында иң күп тикшерелә торган төшенчә. Бу турыда телсезләр һәм ялкаулар гына үз фикерен әйтми калды бугай инде. Ләкин, төп парадокс шунда: бу төшенчәгә аларның һәрберсе үз мәгънәсен сала. Кайбер дин эшлеклеләренең бу төшенчәдән, гомумән, баш тартырга теләве аңлашыла да, чөнки бу төшенчәне кулланган вакытта семантика болганчыгына кереп батарга мөмкин.

"Нәрсә ул традицион ислам?" соравы - бүген иң күп бирелә торган сорауларның берсе. Шушы мәкалә кысаларында бу сорауга җавап бирергә тырышып карыйк әле.

### *ТРАДИЦИОН ИСЛАМ НӘРСӘ УЛ?*

"Традицион ислам" төшенчәсен мөселманнарның дини мохитендә беренче тапкыр 1990 нчы еллар башында Тәлгать Таҗетдин тәкъдим иткән дип исәплиләр. Аңа кадәр бу төшенчә кулланылмаган, ә бәлки, гомумән булмагандыр да. Ләкин эш Тәлгать хәзрәттә түгел. Әгәр дә концепт чамасыз зур популярлык ала икән, димәк, җәмгыятьтә аңа зур ихтыяҗ бар, ул чынбарлыкта булган иҗтимагый процесс һәм карашларны чагылдыра.

Күп кенә басмаларында мөселманнар үзләре бу терминның барлыкка килүен, тимер пәрдәләр җимерелеп, чит ил эмиссарларының идеологик экспансиясе өчен шлюзлар ачылгач, гасырлар дәвамында безнең җирләрдә сакланып килгән чын исламны, Россия чынбарлыгына ташкын кебек агылган төрле сектант аңлатулардан, ә иң беренче чиратта, исламның "ваһһабилык" яки "сәләфилек" кебек (аларның бу атамаларны куллануларының никадәр корректлы булу мәсьәләсе аерым бер сөйләшүне сорый. - Автор искәрмәсе) сәясиләштерелгән формаларыннан аралап алу өчен зарурлык килеп чыгуы белән аңлаталар.

Чын ислам дип бар дөньяда да сөнни күпчелекнең ортоксиясен атыйлар. Аутенистик ислам әдәбиятында бу ортодоксия - Әһле сөннәт вәл җәмәгать дип билгеләнә. Совет чорыннан соңгы күп россиялеләр өчен бу әйтеп тә булмый торган катлаулы бер гыйбарә булып кабул ителә. Бу - "традицион ислам" төшенчәсе барлыкка килүнең икенче сәбәбе. Россия җәмгыятенә, исламның читтән кертелгән төрле аңлатулары белән дискуссияләр алып бару өчен җиңелрәк аңлашыла, үзләштерелә торган нинди дә булса яңа бер термин тәкъдим итәргә кирәк иде. Башка сүз белән әйткән вакытта, "традицион ислам" - чарасызлыктан кабул ителгән төшенчә, һәм ул иң беренче чиратта Россия аудиториясенә ориентлашкан.

"Традицион ислам" төшенчәсенең рус телле килеп чыгышы һәм шартлылыгы, аның турында татарча фикер йөртергә тырышкан вакытта аеруча сизелә. Мәсәлән, 2012 нче елның азагында "Татарстан - Яңа гасыр" телеканалы "Кара-каршы" тапшыруы кысаларында шул теманы карады. Тапшыруга чакырылган экспертларның берсе дә программаның төп темасы булган "традицион ислам" төшенчәсенә татарча төгәл тәрҗемә бирә алмады. Нәтиҗәдә, тапшыруда катнашучы ун кеше татар теленә тәрҗемәсез калдырылган "традицион ислам" сүзен кулланырга мәҗбүр булды.

### *ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕ*

Бу гыйбарә үз тормышы белән яшәп китте, аны, баштагы антисектант мәгънәсеннән читкә китеп, башлангыч вакытындагы "Әһле сөннәт вәл җәмәгать" төшенчәсенең тиңе итеп түгел, ә аерым бер мәгънәле төшенчә итеп файдалана башладылар. Ә гыйбарәнең семантикасы аны төзүче сүзләр белән билгеләнә башлады. "Традицион ислам" гыйбарәсендәге игътибар үзәге әкренләп "ислам" һәм "традицион" сүзләре мәгънәләренә күчте. Интеллектуаль баталияләр хәзер нәкъ менә шул өлкәдә бара

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### МӨФТИЛӘР МӘСКӘҮДӘ ОЧРАШТЫ

**6 нчы ноябрьдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәскәүдә булды һәм берничә очрашуда катнашты.** Аерым алганда, ул Чувашстан һәм Мәскәү, Мәскәү өлкәсе мөфтие Әлбир Крганов, Хант-Манси - Югра автономияле округы мөфтие Таһир хәзрәт Саматов белән очрашты. Очрашу вакытында сүз диния нәзарәтләре арасындагы мөнәсәбәтләр, хезмәттәшлек юллары һәм Россиядә мөселманнар тормышы хакында барды.

### ЯШЬЛӘР АРАСЫНДА ШАШКА ТУРНИРЫ УЗДЫ

**Казанда мөселман яшьләре арасында шашка буенча турнир үткәрелде.** Турнирда Казанның Солтан, Хөзәйфә, Гадел, Нурулла, Сөләйман, Ал, Борнай мәчетләренә йөрүчеләр, шулай ук Россия ислам институты, "Ак өмет" мөселман пансионаты, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләре җыелган иде. Турнир Ярдәм мәчетендә узды.

Мөфти урынбасары, иҗтимагый проектлар җитәкчесе Илдар хәзрәт Баязитовның билгеләп үтүенә караганда, яшьләрне мәчетләргә спорт һәм социаль чаралар аша җәлеп итү мөһим. Турнирны оештыручы "Ярдәм" илкүләм хәйрия фонды җитәкчесе Илһам Исмәгыйлов алга таба да Казанда яшьләр өчен төрле проектларны тормышка ашыру көтелүен әйтте.

Шашка турнирында беренче урынны РИИ студентлары алды, икенчедә - "Ак өмет" мөселман пансионаты, өченче урын - Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә шәкертләрендә.

### САБЫЙЛАР "ГАИЛӘ"ДӘ ТӘРБИЯЛӘНӘ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте көзге каникул көннәрендә мәктәпкәчә яшьтәге һәм укучы балалар өчен Казанның Гаилә мәчетендә мөселман лагере оештырды.** Анда балалар ислам нигезләре һәм йолаларын, әхлак дәресләрен өйрәнә, шулай ук халкыбызның рухый кыйммәтләре белән дә таныша. Укулар рус һәм татар телләрендә алып барыла.

*Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

## Укырга уңайлы булачак

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Коръән өчен гарәп язуының яңа каллиграфик стилен әзерләүче эшче төркем белән җыелыш үткәрде. Яңа шрифтны танылган хәттат (каллиграф), дүртенче хәлиф Гали ибне Әбу Талибтан башлап мөселман каллиграфлары чылбырын дәвам итүгә иҗазәте булган Рамил Насыйбуллов эшли.**

Эшче төркемгә Коръәни-Кәрим белгечләре, Россия ислам институтындагы Коръәнхафизларны әзерләү үзәге җитәкчесе Ибраһим Сабиров, шулай ук Диния нәзарәтенең Коръәнне өйрәнү бүлеге җитәкчесе Илнур Хәйруллин керде. Илнур Хәйруллинның Пәйгамбәребездән (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булса иде) башланган, Россиядә традицион саналган Коръән уку буенча билгеле бер чылбыр - "Хәфс ган Гасыйм"га иҗазәте бар.

Яңа шрифтны әзерләү мөфти кушуы буенча инде берничә ай дәвамында алып барыла. Гарәп язуының яңа каллиграфик стиле әзер булгач, Диния нәзарәте шуның нигезендә язылган Коръән нәшер итәргә җыена. Шунысын әйтергә кирәк, бу укыр өчен уңайлы, безнең җирлеккә хас каллиграфик үзенчәлекләрне исәпкә алып әзерләнгән уникаль шрифт булыр дип көтелә.

## Бердәмлеккә мәдхия

**"Татарстан - уртак йортыбыз" республикакүләм этномәдәни фестиваленең быелгысына Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында гала-концерт белән нокта куелды.**



Театр фойесында ук республика җитәкчелеге вәкилләрен каршы алырга Татарстанда эшләп килгән төрле милләтләрнең иҗат коллективлары җыелган иде. Олы кунакларны - ТР Дәүләт Советы рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары - ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты җитәкчесе Александр Терентьев, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һ. б. рәсми затларны алар рус, татар телләрендәге җырлар, төрле халыкларның традицион биюләре, балалар коллективлары чыгышлары, ак калач һәм чәк-чәк белән каршы алды. Кунакларны исә Халыклар дуслыгы йорты директоры Ирек Шәрипов озатып йөрде.

Илебезнең халыклары бердәмлеге көне белән котлау өчен башлап сүз алган ТР Дәүләт Советы рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин, бөтен Россия төбәкләре халыклары үзләренең бердәмлеген, татулыгын, уңганлыгын күрсәтергә тырыша, республикабызда да шулай ук, дип билгеләп үтте. Этномәдәни фестиваль өч этапта узды, аның барышында республика күләмендә иң яхшы коллективлар һәм аерым башкаручылар сайлап алынды, биредә аларның иң-иңнәре иҗаттагы осталыгын күрсәтәчәк, ә талантлар бездә гаять күп, диде ул һәм Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның мөрәҗәгатен укыды.

"Мөхтәрәм татарстанлылар! Сезне Россия Федерациясенең дәүләт бәйрәме - Халыклар бердәмлеге көне белән чын йөрәктән котлыйм. Бу бәйрәм елдан-ел күбрәк кешене җәлеп итә бара, ул Татарстан Республикасы дип аталган ил-йортыбызда яшәүче барча халыкларны дуслыкта берләштерүгә корылган", - дип, Татарстан Президенты Р.Миңнеханов уртак йортыбызда тыныч һәм игелекле тормыш теләгән.

Халыклар бердәмлеге көне белән котларга килгән Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, мөхәррәм аеның, һиҗри буенча яңа 1435 нче елның беренче көне, шулай булгач, ай календаре буенча Яңа ел белән дә котлыйм, диде. Безнең республикабызның төрле халыкларның бердәмлеге буенча бөек илебезнең калган төбәкләре өчен генә түгел, башка бик күпләр өчен дә олуг үрнәк булуын күреп-белеп торабыз, дип искәртте ул. Казан һәм Татарстан митрополиты Анастасий, 1612 нче елда руслар һәм татарлар, башка халыклар Казан ополчениесенә берләшеп, поляк илбасарларыннан Мәскәүне азат итүдә катнашкан, 400 елдан артык бу игелекле һәм күпне күргән җирлектә барлык халыкларыбыз тынычлыкны саклап яши, дип ул да тынычлык-татулык кыйммәтенә игътибарны юнәлтте.

Татарстанда гомер итүче төрле милләт халыкларының бер-берсен кабатламас җырлы-биюле чыгышлары дустанә яшәүнең туар көн өчен ышанычлылыгы, яшәр өчен бердәмлекнең кирәклеге, шулай тормыш итеп була алган төбәкнең күркәмлеге турында иде.

*Миләүшә*
***НИЗАМЕТДИНОВА,***
*"Татар-информ"*

# ТРАДИЦИОН ИСЛАМ ТИРӘСЕНДӘГЕ МӘГЪНӘВИ КҮПТӨРЛЕЛЕК

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

да инде. Дискуссияләрдә катнашучылар хәзерге вакытта традиционлык критерие булып нәрсә тора, бу вакытта нинди традиция күз алдында тотыла, динне традицион һәм традицион булмаган диннәргә бүлү дөресме һ. б. сораулар өстендә баш вата.

Юк урында килеп чыккан бу дискуссия нәтиҗәсендә традицион ислам төшенчәсенең берничә интерпретациясе барлыкка килде. Ислам чынбарлыгын аңлауны җиңеләйтергә тиешле неологизм, шулай итеп, киресенчә, барысына да буталчыклык кертте.

### *"ТРАДИЦИОН ИСЛАМ"-НЫҢ ДҮРТ МӘГЪНӘСЕ*

Төрле текстларның бу проблема уңаеннан каралган анализлары "традицион ислам" төшенчәсенең дүрт төп мәгънәдә кулланылуын күрсәтә. Бу семантик мәгънәләр бер-берсенә салынган сфералар кебек өлешчә үзара кисешәләр һәм, нигездә, аларны гомуми бер күренешнең төрле яклары, аерым бер элементлары итеп карарга була. Әмма, дискуссияләрдә катнашучылар үзләре алай дип исәпләми. Әйдәгез, бу гыйбарәнең шул мәгънәләрен карап китик.

"Традицион ислам" төшенчәсенең беренче мәгънәсен Россия исламы дип аңлатырга була. Гыйбарәне бу мәгънәсендә дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре куллана. Алар өчен, иң беренче чиратта, Россия мөселманнарының үз дәүләтчелекләрен яклавы, башка конфессия вәкилләре белән үзара дус һәм тату яшәүләре мөһим. Алар "традицион ислам" дигән вакытта нәкъ менә шуны күз алдында тота.

"Традицион ислам"ның икенче мәгънәсен халык исламы дип аңлатырга була. Кагыйдә буларак, гыйбарәне бу мәгънәсендә номиналь, этник мөселманнар куллана. Аларның исламы диндар әбиләре турындагы истәлекләреннән ерак китми. Башка сүзләр белән әйткәндә, бу очракта тәгълимати ислам, ислам кануннары буенча ул ничек булырга тиешлеге турында сүз бармый, ә мөселманнарның дәһрилек чорларыннан соң өлешчә деформацияләнеп сакланып калган элеккеге реаль дини практикасы калдыклары турында сүз бара. Халык исламы белән этнографлар нык кызыксына, ул традицион ислам дошманнарының ярсулы һөҗүмнәренә дучар була, алар аны кимсетергә тырышып "бабайлар исламы" дип атарга тырыша, гәрчә бу сүзләрдә бернинди дә тискәре мәгънә булмаса да.

Традицион исламның өченче мәгънәсе - милли ислам (татар исламы). Татар исламы милләт казанышы буларак карала, ул, бер яктан, татар халкының тарихый мирасының бер өлеше булып тора, ә икенче яктан, аның алга таба яшәп калуының шарты буларак карала. Бу вакытта татар милләтчеләре "татар исламы"на төрлечә акцент куя. Кайберләре өчен (беренче чиратта дөньяви милләтчеләр өчен), бу - җәдитчелек, ә икенче берләре (беренче чиратта диниләре) өчен, бу - кадимчелек, ягъни, консервативлык.

Һәм ниһаять, традицион исламның дүртенче мәгънәсе - йолаларны башкарып барган мөселманнарның үзләре аңлавындагы мәгънәсе. Мондый аңлауда традицион ислам - бар ислам дөньясында борынгы вакытларда ук булган ортодоксаль ислам. Башка сүзләр белән әйткәндә, бу Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булса иде) үзенә үк барып тоташкан өч дини фән - кануни хокук, догматик илаһият һәм дини этика белән вәкаләтләнгән ислам. Ислам ортодоксиясенең мәгънәсе һәм асылы да шунда, "Әһле сөннәт вәл җәмәгать"тә.

Традицион исламның төп дошманнары булган сәясиләшкән ислам тарафдарларын сектантлар дип нәкъ менә шуңа атыйлар да, чөнки алар исламның ортодоксальлеген юкка чыгарырга тырыша. Беренчедән, алар ислам хокукындагы кануни мәктәпләрне (мәзһәбләрне) танымый, гәрчә кайвакыт нindидер бер конъюнктур ниятләр белән, күз буяр өчен тышкы яктан хәнәфи мәзһәбе тарафдарлары булып күренергә тырышсалар да. Икенчедән, алар исламның Коръән һәм Пәйгамбәр (с. г. в.) өйрәтүләрен бар тулылыгында ача торган догматик мәктәпләрен катгый инкарь итә, шул исәптән аеруча дини толерантлыгы белән аерылып торган мәтуриди мәктәбен дә. Ә татарлар һәрвакыт шул мәктәп тарафдары булган. Һәм, өченчедән, алар исламның рухый этикасы белән аяусыз көрәш алып бара, ә рухый этиканы йөртүче булып традицион рәвештә суфыйчылык чыгыш ясаган. Шулай итеп, сәясиләшкән ислам бернинди дә чиста ислам түгел (ә алар үзләрен чиста ислам тарафдарлары дип атый), ә гади бер дини секта.

### *ВИНОГРАД ТУРЫНДА ХИКӘЯТ*

Традицион ислам тирәсендәге мәгънәви күптөрлелек төрле буталчыклыклар китереп чыгара һәм бу турыда дискуссия алып баруның бернинди дә мәгънәсе калмый. Семантик бу буталчыклык Җ.Руминың виноград турындагы билгеле хикәятендә бәян ителгән вакыйганы көзгедәге кебек төгәллек белән чагылдыра. Бу хикәяттә төрле халык вәкилләре бер җимеш турында уртак фикергә килә алмаган, чөнки алар бер-берсен аңламаган, гәрчә аларның һәрберсе шул бер үк җимешне үз телендә әйткән булган. Бу мәкаләдә каралган очракта да без бер үк аталышның җилпәзә кебек төрле мәгънәләргә таркалуын күрәбез. Ләкин бу очракта да шул ук нәтиҗә - уртак фикергә килү мөмкин түгел.

Әлеге терминологик экскурс илебезнең иҗтимагый-дини вәзгыятен төшенергә теләгән кешеләргә ярдәм итәр дип өметләнәм. Предметны белмәү аркасында күп спекуляцияләр килеп чыга. Иң аянычы шунда - монда традицион ислам - чын ислам, Пәйгамбәр (с. г. в.) исламы төшенчәсе үзе дискредитацияләнә. Ә бит бары тик шул ислам гына бар мөселманнарны да берләштерә һәм безнең җәмгыятебезгә тынычлык һәм татулык бүләк итә алачак. Моңа безнең һәрберебез дә мохтаҗ.

***Рөстәм БАТЫР,***
***Татарстан мөфтиенең***
***беренче урынбасары***

**Россия һәм Татарстан Мөслимәләре берлеге рәисе Наилә ханым ҖИҺАНШИНА белән сөйләшүебез, төрле сәбәпләр чыгып, һаман кичектерелеп килә иде. Газетабызның узган санында басылып чыккан "Иң яхшысы - сарык кебек хатын" дигән язма (№ 15-16) очрашуны тизләтте дә куйды. Хикмәт шунда - ул язманы укыган күп кенә мөслимәләр безгә үпкә белдереп шалтыратты. Юкса үзем, холкың сарыкныкыдай булса, бу тормышта күп нәрсәләрне саклап калырга мөмкин икән, дип күңелемә беркетеп куйган идем. Хәер, монысы минем фикер... Шулай итеп: "Бүгенге мөслимә, чыннан да, нинди булырга тиеш?" - дигән сорау белән Наилә ханымга мөрәҗәгать итәбез.**

# ИРЕҢ ӨЧЕН УКЫЛГАН КИТАП БУЛМАСКА КИРӘК



- Сарык кебек аңгыра булганы яхшы, диелсә, әлбәттә, мин дә үпкәләгән булыр идем. Монда имам Газзали бәрәкәт күп булган, мөбарәк, Аллаһы Тәгаләгә итагатьле хатын-кыз турында әйтә бит. Бүгенге заман мөселман хатын-кызы әле оптимист та булырга, хөр фикер белән дә яшәргә тиеш, минемчә. Әти-әниең кушканга яки күбрәк түләгән өчен түгел, ә җаныңа якын эшне сайлап алырга кирәк. Һәм, әлбәттә, безнең җәмгыятькә файдалы шәхес булуыбыз да бик мөһим. Күп очракта хатын-кыз кияүгә чыгып, балалар таба да аның тормышында кызыклы шөгыльгә, кызыклы очрашуларга урын калмый. Балалар карау, савыт-саба юу, өйне җыештыру - берзаман бу хатын-кыз белән әнә шулар турында гына сөйләшеп була башлый. Менә шуннан соң иренең хатыны белән кызыксынуы, аңа соклануы арта барыр микән? Никадәр генә кызыклы булмасын, укып чыккач, китапны читкә алып куябыз бит, үз ирең өчен менә шул укылган китап булып калмаска кирәк. Кыз бала югары белем алырга, хәтта яшьтән кияүгә чыккан очракта да иренә, син мине укытасың, дигән таләпне куярга тиеш. Күптән түгел генә безнең Гаилә кору үзәгенә бер бик бай мөселман ир-аты кәләш эзләп килгән иде. Өйләнешүгә мин аны Европаның үзе теләгән теләсә кайсы югары уку йортында укытачакмын, ди. Әлбәттә бездә: "Сез булачак хатыныгызның гына түгел, балаларыгызның да киләчәген тәэмин иткәнсез бит инде. Көчен, нервларын, вакытын сарыф итеп укып йөрү аңа нигә кирәк?" - дигән сорау туды. Моңа каршы ул болай дип җавап бирде: "Мин мөселман буларак, киләчәкне уйламыйча яши алмыйм. Минем гомерем Аллаһ кулында. Ә акча һәр көн килеп тормаса бетәргә дә мөмкин. Ул чагында хатыным гаиләне ничек тәэмин итәр? Аның дипломы, киләчәккә ышанычы булырга тиеш". Менә бу чын мөселман сүзе ичмаса!

***- Ышаныч дигәннән, Сез җитәкләгән Мөслимәләр берлеге дә менә инде сигез ел дәвамында канаты каерылган, хәсрәткә баткан хатын-кызларга бу тормышта ышаныч бирә.***

- Әйе, Аллаһның рәхмәте белән шактый актив эш алып барабыз. Әле менә күптән түгел генә бер хатын эш эзләп килгән иде. Ире юк, эше юк, торыр урыны да юк, баласына биш яшь. Аны эшкә урнаштыру өчен башта баласын балалар бакчасына бирергә кирәк. Ә аның пропискасы юк. Тоттык та кияүгә бирдек үзен, шуның белән бөтен проблемасы хәл ителде. Хатыннарга ярдәм итәр өчен оештырылган проектларыбыз файдалы булып чыга. Парны бәндәсенә Раббыбыз үзе бирә, әмма бер-берләрен тапсыннар өчен аның сәбәбе кирәк. Гаиләләрне саклап калуда да ярдәм итәргә тырышабыз. Мөселман гаиләләре арасында аерылышучылар саны дөньявиларныкыннан ким түгел хәзер. Аллаһ кануннары белән яшәп тә нишләптер берберләрен аңламый башлыйлар. Ире белән аралары суынуны, ягъни "авыру"ның беренче билгеләрен сизеп алуга мөрәҗәгать итсәләр, әлбәттә, моны бергәләп хәл итеп була. Безнең киңәшләр буенча хатын-кыз тиз генә ялгышларны дөресли башлый. Соңыннан: "Хәзер бик матур яшибез, ирем мине элеккегә караганда да ныграк ярата", - дип рәхмәт әйтеп тә китә әле.

Тагын бер күркәм проектыбыз бар - дизайнерлар белән эшли башладык. Моңа кадәр дизайнер сүзе бездә кулланылмады, чөнки бу тормышыбызда юк әйбер иде. Мин кайсы гына чит илгә барсам да шуңа игътибар итәм - һәр халык үзенең традицион киеменнән йөри анда. Согуд Гарәбстанында, мәсәлән, сари кигән хатын-кызны күргәнем юк, ә Һиндстанда чадра ябынган хатын-кыз очрамый. Ә бит безнең дә шәригатькә каршы килми торган үз милли киемебез бар. Һәм ул безгә бик килешеп тора. Мәҗлесләрдә абыстайларыбызга күз салыгыз сез - шундый матурлар бит алар. Без дә шулар кебек булсак иде... Әнә шундый нияттән чыгып башланган эшебез хәзер елдан-ел киңрәк колач җәя бара. Дизайнерларыбызның эшен инде хәзер чит илгә чыгарырга да оят түгел, аларны Италиядә, Төркиядә дә күреп, бик сокландылар. Хәтта кызларыбызны чит ил фирмалары эшкә дә чакырды. Бу юнәлештә тагы да үсәргә - эшебезне Россия күләмендә дә активлаштырырга уйлыйбыз.

Әле безнең ак яулыклы абыстайларыбыз бар. Әлмира абыстай Әдиятуллина шул абыстайлар шурасын җитәкләр дип өметләнеп торабыз. Чөнки бу ханымнар гомер буе иҗтимагый тормышта катнашып килде. Аларның хәзер балалары, оныклары үсеп беткән, буш вакытлары күп, эш өчен йөгереп йөри торган иң дәртле чаклары.

Мөслимәләребезне тагын бер шатлыклы хәбәр белән куандырасым килә. Җөмһүриятебезнең мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Мөслимәләр берлеге өчен аерым бина эзли. Бу безгә эшчәнлегебезне тагын да киңәйтергә мөмкинлек бирәчәк.

***- Сез әле күптән түгел генә кызларны-егетләрне бергә аулагөйгә дә җыйдыгыз...***

- Бу шәригатькә сыямы, дип сорыйсыгыз киләдер инде. Ир-ат өйләнгәндә хатын-кызны күрергә тиеш. Һәм ул аны күрә, никадәр генә тәкъва булса да, берсенең дә күзләрен бәйләп йөргәне юк әле. Ә аулагөйдә без аларны аерым табынга утыртабыз. Бу уй беләсезме нәрсәдән килеп чыкты? Гаилә кору үзәгенә барлыгы мең ярымнан артык кеше килде. Аларның кайсысы кемгә туры килүен сайлавы да бик авырлашты. Шуңа күрә яшьләре, холыклары туры килгәннәрен барлап, аулагөйгә чакырдык. Соңгы очрашуга йөз кеше килгән иде, без бу юлы каенаналар турында сөйләштек. Кызларның каенана турында фикер алышуларын егетләрнең нинди зур игътибар белән тыңлавын күрсәгез икән сез! Бу хатын-кыз минем әниемә нинди мөнәсәбәттә булыр, дигән уй белән утыра бит инде алар. Хатын-кыз гына түгел, ир-ат үзе дә ихтирамлы, тәрбияле булса гына бәхетле гаилә туа. Кызганычка, бүгенге мөселман ир-атлары хатын-кыз миңа хезмәт итәргә тиеш дип саный. Әмма ул шуны белергә тиеш: хатын-кызны бары тик яратып кына үзеңә хезмәт иттереп була. Тагын шундый хәл күзәтелә: башта булачак хатынына тыйнак булырга, күп күрмәскә, күп белмәскә дигән таләпләр куелса да, өйләнешкәч, ир-атка актив, шат, шаян хатын-кыз кирәк була башлый. Әле кайберләре беренче хатыннарыннан көндәш эзләтә. Мескен хатын, башка чарасы калмагач, безгә килә. Ир-ат хатын-кызга өйләнә икән - ул аны бәхетле итәргә тиеш. Ул үз әнисен ярата, җәннәтнең әнисенең аяк астында икәнен белә бит. Синең хатының да - ана. Синең балаларыңның җәннәте аның аяк астында. Хатынын елаткан, рәнҗеткән ир-ат җәннәткә керер дип уйламыйм мин.

***- Наилә ханым, сөбханалла, Сезнең шундый күркәм гаиләгез бар. Ильяс хәзрәт белән ике ир бала тәрбияләп үстердегез. Бу кадәр колачлы эш алып баргач, гаиләгезгә вакытыгыз каламы?***

- Аллаһ Раббыбыз миңа шундый ир бирде - ул мине аңлый, бер-береңне аңлап яшәү зур бәхет бит ул. Әйе, өйгә арып-талып кайткан чаклар да була, миңа хәзер балалар ярдәм итә башлады. Ризыкны да әзерлиләр, өйне дә җыештырып куялар.

***-Хәзрәтнең: "Син минем хатыным, матурлыгың да минем өчен генә. Беркая да бармыйсың, өйдә генә утырасың!" - дигәне булмадымыни?***

- Булды, кавышкач ук әйтте ул аны. Миңа өйдә утыра торган хатын кирәк, диде. Моңа бер дә каршы килмәдем. Юкса мин журналист идем бит, телевидениедә дә эшләдем, иҗтимагый яшьләр оешмасы да оештырган идем. Әмма кияүгә чыгу минем өчен изге гамәл булды. Никахлашу белән эштән чыктым. Аннары бер-бер артлы балалар туды. Ана назына туймаган сабыйны чит кешегә калдырып, эшкә чыгып китүне мин дөрес дип санамыйм, әни кеше үз бурычын тулысынча җиренә җиткереп үтәргә тиеш. Мин аларга догалар да ятлаттым, укырга-язарга да өйрәттем. Мәктәп алдыннан гына, коллективка ияләшсеннәр дип, бакчага бирдем. Алар мәктәпкә киткәч, кинәт кенә буш вакытым артты. Ә җәмгыятебездә никадәр җитешсезлек, күпме гаделсезлек икән - шуларны күрә башладым. Аны савыктыру өчен һәркем кулдан килгәнне эшләргә тиеш ләбаса. Көннәрдән беркөнне мин иремә: "Берни дә эшләмичә, тыныч кына яши алмыйм", - дидем. Ул мине аңлады.

**Нәүбәһар КӘБИРОВА**

## Телемарафонга беренче нәтиҗәләр ясалды

**"Зәкят" хәйрия фонды Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Корбан бәйрәме уңаеннан оештырган "Сөючеләр фида кыла" акциясенә беренче нәтиҗәләрне ясады.**

Белгәнебезчә, Диния нәзарәте "Яңа гасыр" каналы белән берлектә 15 нче октябрьдә "Сөючеләр фида кыла" телемарафоны уздырган иде. Әлеге телемарафон физик мөмкинлекләре чикле ятим балаларны тернәкләндерү приюты бинасын төзекләндерүгә ярдәм итү максатыннан үткәрелде.

Бүгенге көндә исәп-хисап счётына банклар аша 91208 сум 48 тиен акча күчерелгән һәм кешеләр үзләре алып килеп исәп-хисап счётына 22146 сум 8 тиен күләмендә акча салган. "ЗАКЯТ" сүзен язып, 7715 номерына җибәрелгән SMS-хәбәрләр ярдәмендә барлыгы 718244 сум тупланган. Шулай итеп, беренчел нәтиҗәләр буенча приют өчен барлыгы 831598 сум 56 тиен акча җыелган.

Әгәр дә бер SMS-хәбәрне 50 сумнан дип санасак, акциядә 15 меңләп кеше катнашканын белә алабыз.

Шунысы да сөендерә, бик күпләр "Зәкят" хәйрия фондына матди ярдәм күрсәтүне әле дә дәвам итә. Хәйрия акчалары Казан шәһәренең Габдулла Тукай урамындагы 3 нче йортта урнашкан "Зәкят" фондында кабул ителә. Инвалид ятимнәргә ярдәм итәргә теләүчеләр 7715 номерына "ЗАКЯТ" сүзе белән SMS-хәбәр дә җибәрә ала. Бер SMS-хәбәрнең бәясе 50 сум (төгәл сумма операторга бәйле). Әгәр дә күбрәк хәер бирергә теләсәгез, "ЗАКЯТ" сүзеннән соң буш урын (пробел) калдырып, сумманы язарга кирәк.

## ЗУР КЛЫКИ БИСТӘСЕНӘ МӘЧЕТ КИРӘК

*Аллаһның ярдәме белән Казан шәһәре Совет районының Зур Клыки бистәсендәге Трудовая урамында Сәлах мәчете төзелә башлады. Тик төзелеш эшләре хәзергә тукталып тора, аны дәвам итү өчен акча кирәк. Әйдәгез, бу савaплы эшкә хәлебездән килгәнчә үз өлешебезне кертик, Аллаһ йортын - Сәлах мәчетен бергәләп төзик!*

**Реквизитлар: ИНН/КПП 1653001805/165801001, ОГРН 1021600000124, БИК 049205805, К/с 30101810000000000805, Р/с 40703810200020000352 в ОАО "АК БАРС" Банк в г. Казани.**

***Элемтәгә керү өчен телефон: 89173914978 (Нурислам хәзрәт).***

**Сайт: www.salyah.ru.**

# ИСЛАМДА ОРГАННАРНЫ КҮЧЕРЕП УТЫРТУ РӨХСӘТ ИТЕЛӘМЕ?

**"Татар-информ" матбугат агентлыгында узган матбугат конференциясендә Татарстан сәламәтлек саклау министры Гадел Вафин, Татарстанда органнарны күчереп утырту программасы әзерләнә, дип хәбәр итте. Министр сүзләренә караганда, бу юнәлештә республикада инде эш башланган: эшче төркем төзелгән, өлкәннәргә һәм кече яшьтәге пациентларга органнарны күчереп утыртуның алдагы өч елга исәпләнгән программа проекты тикшерелгән. "Безнең алда бөер, бавыр һәм йөрәкне күчереп утыртуны җәелдерү, алга таба трансплантациянең яңа төрләрен, аерым алганда, ашказаны асты бизен күчереп утыртуны үзләштерү мәсьәләсе тора. Соңгысы - үпкәләрне күчереп утырту булачак", - ди Гадел Вафин.**

**Сүз уңаеннан, быел Татарстанда бөер, бавыр һәм йөрәкне күчереп утырту буенча 17 операция ясалган.**

**Әлеге мәсьәлә буенча мөселманнар арасында да, дөньяви кешеләрдә дә күп төрле, еш кына каршылыклы сораулар туа. Чыннан да, исламда трансплантация рөхсәт ителәме? Рөхсәт ителсә, кайсы очракта, нинди шартларны үтәгәндә моны тормышка ашырырга ярый? Бу четерекле сорауларның кайберләренә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН җавап бирә.**



***Бер кешедән икенчесенә аның органнарын күчерү рөхсәт ителәме?***

Органнарны күчереп утырту XX гасырда гына барлыкка килгән күренеш. Ләкин ислам фикыһында бу яңалык түгел. Мөселман хокук белгечләре бу турыда күптән фикер йөртә. Хәнәфи мәзһәбенең төп фикерләрен теркәгән һәм системалаштырган Әбу Хәнәфи шәкерте Мөхәммәд ибне Хәсән әш-Шәйбани болай дигән: "Сарык, сыер, дөя, ат һәм башка хайваннарның сөякләрен дару буларак куллану тыелмаган. Чыгарма булып кеше һәм дуңгыз сөякләре тора. Кеше һәм дуңгыз сөякләрен куллану тыелган".

Моны нигез итеп алсак, кеше органнарын куллану тыела. Хәнәфи мәзһәбе китапларында бу фикер киң таралган. Дәлил буларак түбәндәге сүзләрне китерәләр: "Кеше хөрмәткә лаек, шуңа күрә аның органнарын куллану исән чагында да, үлгәч тә тыела".

Имам Шәфигый мәзһәбенә килсәк, кеше һәм хайван органнарын куллану аерым очракларда рөхсәт ителә.

"Минхаҗ ат-Талибин" китабында имам ән-Нәвави искәртә: "Пакь нәрсә таба алмаса, кеше сөякләргә нәҗес куша ала. Ләкин пакь нәрсә тапкан очракта, ул нәҗесне алып атарга тиеш, нәҗес аңа зарар китермәсә дә".

Икенче хезмәтендә ул: "Бик кирәк булган очракларда, шәфигый мәзһәбе буенча, үлгән кеше итен ашарга ярый", - ди.

Гиз ибне Абд әс-Сәлам болай ди: "Әгәр кем дә булса чиктән тыш хәлләрдә мәет таба икән, ул аның итен ашый ала, чөнки мәет итен ашауның зарары ачлыктан үлүгә караганда кимрәк".

Акыл исә безгә үлгән кеше органнарын башка кешегә күчерүнең рөхсәт ителүен күрсәтә, чөнки күчереп утыртылмаган органнарны бөҗәкләр ашый һәм алар вакыт үтү белән кабердә таркала.

Мәлики мәзһәбе галимнәре, гадәттән тыш хәлләрдә органнарны күчереп утырту рөхсәт ителә, дигән бер фикергә килә.

Фикыһ буенча ислам шурасы органнар трансплантациясе рөхсәт ителү турында карар чыгарды. Аның карарында органны күчереп утыртып, кеше гомерен саклап калуның органы күчереп утыртылган кешене берничек тә нәҗесләмәве, чөнки органны күчереп утыртуның яхшылыкка юнәлтелгән эш булуы, авыру кешегә зур булышлык күрсәтүе турында әйтелә.

Трансплантация шәригать тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

- органны алу донорга зарар китермәгәндә;
- органны донор үзе теләп биргән очракта;
- авыру кешенең терелүе өчен трансплантация бердәнбер медицина чарасы булса;
- трансплантация уңышлы чыкса.

**Органнарны күчереп утыртуны рөхсәт иткән күрсәтмәләр**

- Кешенең тормышын саклап калу өчен мәет органнарын кучереп утырту бу кешенең балигъ булуы, психик сәламәтлеге һәм шулай ук әлеге операциягә рөхсәт булу белән бәйле.
- Кешегә күчереп утыртыла торган органнар ите ашарга яраклы булган чиста хайваннардан, ахыр чиктә генә башка хайваннардан алынырга тиеш.
- Бер үк кешенең органын, мәсәлән, тирене, сеңерне, сөякне һ. б. бер урыннан икенче урынга күчерү бик кирәк булганда гына башкарылырга тиеш.
- Әгәр дә авыруны дәвалау өчен металлдан органнар ясау мөмкинчелеге бар икән, мәсәлән, йөрәк клапаннарын, кул яки аяк протезларын, металлдан яки башка ясалма матдәләрдән ясалган охшаш әйберләр кулланырга мөмкин.

Шәйх Хәлил Абдулкәрим Гуненж Фикыһ буенча ислам шурасының органнарны күчереп утырту шартларын каравын, ләкин эзлеклелеккә кагылмавын билгеләп үтә. Ягъни, органнарны күчереп утырту мәсьәләсе чишелгәндә, түбәндәге эзлеклелек сакланырга тиеш:

- әгәр дә мөмкинчелек булса, ясалма материалларны нәрсәдән эшләнүенә карамастан кулланырга;
- әгәр дә ясалма материал юк икән, итен ашарга яраклы чиста хайван органнарын кулланырга;
- әгәр дә юк икән, эт һәм дуңгыздан кала башка хайваннарның органнарын кулланырга;
- әгәр дә анысы да юк икән, эт һәм дуңгыз органнарын кулланырга;
- әгәр дә анысы да булмаса, кеше мәете органнарын кулланырга;
- әгәр дә инде анысы да булмаса, сәламәтлегенә зыян китермичә генә, исән кешенең органнарын кулланырга.

Җенси органнарны күчереп утырту катгый тыела, чөнки, табиблар әйтүе буенча, җенси органнар йөклелек вакытында да тәэсир итә. Алар орган кучереп утыртылган кешегә донорның үзлеген күчерә. Шушы сәбәп аркасында, җенси органнарны күчереп утырту хәрәм булып исәпләнә.

**Кешенең йөрәген күчереп утырту буенча ни әйтерсез?**

Җан тәннән чыккан мизгелдә кеше үлә. Бөтен тәндә кан әйләнешен тәэмин итеп торган йөрәк туктый. Йөрәк туктавы белән кан әйләнеше дә туктый. Табиблар сүзенә караганда, йөрәк туктап, берничә минут узгач, баш мие күзәнәкләре үлә башлый. Бу үлемнең йөрәк һәм баш мие коруы белән бәйлелеген күрсәтә. Әгәр дә йөрәк туктаса, ә баш мие эшчәнлеген дәвам итсә, кеше үлмәгән дип исәпләнә, чөнки йөрәк яңадан эшләп китәргә мөмкин.

Мәетне юу, кәфенләү, идда (ире үлгәч хатынына кияүгә чыгарга ярамый торган вакыт), мирасны кабул итеп алу кебек дини күрсәтмәләр шушы ике орган эшләүдән туктагач кына гамәлгә керә башлый. Шуңа күрә кешенең эшләп торучы йөрәген башка кешегә күчереп утыртырга ярамый. Шулай ук мондый хәлдә булган кешенең калган органнарын да, үлгән дигән нәтиҗә чыгарып, башка кешегә күчереп утыртырга ярамый.

Әйе, кайчакта баш мие үлгәч тә, йөрәк эшләвен дәвам итә, һәм бу кешенең исән калуына өмет булмый, ләкин бу очракта да кеше йөрәге эшләп торган вакытта тере дип исәпләнә.

## КАЙГЫРТУЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ

**"ДУМ РТ Хадж" - Согуд Гарәбстанында хаҗиларга тулы медицина ярдәме күрсәтә алган Россиянең бердәнбер хаҗ операторы. Бу Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы белән алдан ук әзерлек эшләре алып баруы, аңлашып хезмәттәшлек итүе нәтиҗәсе.**

Быел хаҗиларны изге сәфәргә 12 табиб озата барды. Алар ярдәм күрсәтү өчен кирәкле дарулар, медицина җиһазлары белән тәэмин ителгән иде. Хаҗ сәфәренең барлык гыйбадәтләрен үтәгәндә дә, экскурсияләргә барганда да хаҗиларны табиблар махсус киемнәрдә, күчереп йөртә торган медикаментлар белән озатып йөрде. Яшәү урынында, хаҗ гыйбадәтләре кылына торган Мина һәм Гарәфә үзәнлегендә медицина ярдәме күрсәтү пунктлары эшләде.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм "ДУМ РТ Хадж" Татарстан Хөкүмәтенә, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына булышлык күрсәтүләре һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек өчен рәхмәт белдерә. "Аллаһы Тәгаләнең ярдәме һәм табибларның олуг хезмәтләре белән хаҗиларга профессиональ медицина ярдәме күрсәтелде. Быелгы хаҗ вакытында үзләренең һөнәри бурычларын югары дәрәҗәдә башкарган һәм 1200 хаҗиның сәламәтлеге сагында торган табибларга ихластан рәхмәтләребезне җиткерәбез", - диелә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте сайтында.

## МЕҢ ДӘ БЕР ХӘДИС

**"Йа Раббым, гыйлемлек белән ярдәм ит, йомшаклык белән зиннәтлә, тәкъвалык белән хөрмәтлә, сәламәтлек белән күркәмлә".**

Бу догаларның һәммәсе Аллаһы Тәгаләдән бер бөек нигъмәт икәнен белеп, даимән шөкрана булырга кирәклеге васыять ителгән.

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №17 (212) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35426.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 7 ноябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**